**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН ТАБЫН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ**
**IV ЧАКЫРЫЛЫШ XLI УТЫРЫШЫ**

**К А Р А Р № 71**

*Югары Табын авылы* *“04” нче март, 2024 нче ел*

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Советының «10» декабрь 2018 елның «Җир салымы турында» гы № 3 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексына туры китерү максатыннан, прокурорның 22.01.2024 № 02-08-01-2024 протестын үтәү максатыннан, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Советының «10» декабрь 2018 елның «Җир салымы турында»гы № 3 карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 .2 пунктның 1 пунктчасының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары (торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез милек объектына туры килә торган җир участогы өлешеннән тыш) яки торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) (торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы өчен сатып алынган (бирелгән) җир участокларыннан тыш эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланыла торган шәхси торак төзелеше)»;

1.2. 1 пунктның икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

1.3. 2 пунктның 4 пунктчасында «торак пунктлар җирләре өлешендә» дигән сүзләрне»торак пунктлар җирләре составында» дигән сүзләр белән алыштырырга;

1.4. 5 нче пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«5. Салым түләү җир кишәрлекләре булган урында башкарыла».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар РФ Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

***Татарстан Республикасы***
***Мөслим муниципаль районы***
***Түбән Табын авыл җирлеге башлыгы*** **Р.Ш. Кыяметдинов**